ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
IV чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
IV созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

КАРАР
от 08.02.2021ел

РЕШЕНИЕ
№07-06

Актаныш муниципаль район Советының 2018 елның 27 апрелендә кабул ителгән 28-06 номерлы «Муниципаль милектә булган урман кишәрлекләрен һәм яшел үсентеләрне булдыру, карап тоту һәм саклау кагыйдәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының бурычлары буенча уртак коллегиясе беркетмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. «Муниципаль милектәге урман кишәрлекләрен һәм яшел үсентеләрне булдыру, карап тоту һәм саклау кагыйдәләре турында» 2018 елның 27 апрелендәге 28-06 номерлы Актаныш муниципаль районы Советы карары белән расланган, муниципаль милектәге урман кишәрлекләрен һәм яшел үсентеләрне булдыру, карап тоту һәм саклау кагыйдәләренә, 9 бүлекнең 9.1 пунктчасына, түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында салым органының белешмәсе».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмати рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында http://aktanysh.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Муниципаль район Башлыгы
Совет Рәисе

Э.Н.Фәттахов